**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ**
# КАРАРЫ

«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» 592-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» 592-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 42-VII ДС

проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Россия Федерациясе Салым кодексының $214^{10}$ статьясы нигезендә салым түләүченең физик затлар керемнәренә салым салу максатларында салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен арттырырга һәм аны 1гә тигез итеп билгеләргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**аңлатма**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2025 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе субъектларына салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемнәре әлеге объектның кадастр бәясеннән кимрәк булган очракта, физик затлар керемнәренә салым салу максатларында салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керем суммасын билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициентны 0,7 дән 1 кадәр арттыру хокукы бирелде.

Хәзерге вакытта Россия Федерациясе Салым кодексының 214.10 статьясындагы 2 пункты нигезендә салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемнәре әлеге объектның Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертелгән һәм сатылган күчемсез мөлкәт объектына милек хокукы күчүне дәүләт теркәвенә алган елның 1 гыйнварыннан кулланылырга тиешле (бу күчемсез мөлкәт объекты салым чоры дәвамында барлыкка килгән очракта – әлеге күчемсез мөлкәт объектының ул дәүләт кадастр исәбенә куелган датага билгеләнгән кадастр бәясе) 0,7 киметүче коэффициентына тапкырланган кадастр бәясеннән кимрәк булган очракта, салым салу максатларында салым түләүченең әлеге күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемнәре әлеге күчемсез мөлкәт объектының 0,7 киметүче коэффициентына тапкырланган тиешле кадастр бәясе тигез күләмдә кабул ителә.

Шул рәвешле, закон 2025 елның 1 гыйнварыннан физик затлар керемнәренә салым салу максатларында күчемсез мөлкәтне сатудан керем сатылган объектның кадастр бәясенә тигез булырга тиеш, дип билгели.

Законны кабул итү Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына керемнәр артуга китерергә мөмкин, аларның күләмен бәяләп булмый.

**«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Салым түләүченең күчемсез мөлкәт объектын сатудан керемен билгеләү өчен кулланыла торган киметүче коэффициент күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.